**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге составына керүче Күки авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

3 декабрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 3 декабрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 90 яшьтән өлкән гражданнардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

1. Күки авылының Ленин, Хәлилов, М.Җәлил урамнары өчен вак таш сатып алу.
2. СИП 2х6мм кабеле сатып алу.
3. Кышкы һәм җәйге чорда Күки авылында урамнарны карап тоту (тору).
4. Күки авылы торак пунктында суүткәргечне ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы, Яңа урам, 5 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Башлыгы А.М.Бәдретдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ РАЙОН СОВЕТ КУКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫ КҮКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Р 05-10224/38
ИНН 1634000362 ОГРН 1021607355043
СОВЕТ КУКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ